وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№8 (105). 7 октябрь 2011 / 10-зөлкагъдә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



"Хәзерге мөслимәләр актив позициядә тора" ▷2◁



Бергәлектә көч! ▷3◁



Тизрәк намазга басасы иде... ▷4◁

### ӨЛКӘННӘР КӨНЕ УЗДЫ

Узган атнаны Өлкәннәр көне уңаеннан ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" фонды җитәкчесе Рөстәм хәзрәт Ясәвиев һәм Мөселман яшьләре берлеге әгъзалары Арчадагы Картлар һәм инвалидлар интернат-йортында булып кайтты. Казаннан килгән кунаклар өлкән буын вәкилләрен бәйрәм белән котлады.

### МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ

Шимбә көнне, ягъни 1 октябрьдә Менделеевск районының Абалач авылында яңа мәчет ачылды. Әлеге тантанада район хакимияте башлыгы Таһир Хөрмәтуллин, ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре, меценатлар һәм авыл халкы катнашты. Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз мәчет төзелешенә ярдәм иткәннәргә рәхмәт хатлары һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

### БӨГЕЛМӘ ШӘҺӘРЕНДӘ ДИНИ ДӘРЕСЛӘР БАШЛАНДЫ

2 октябрьдән Бөгелмә үзәк мәчетендәге башлангыч мәдрәсәдә яңа уку елы башланды. Оештыру җыелышында илледән артык кеше катнашты. Очрашуны Бөгелмә районы имам-мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйруллин дин гыйлеменең фазыйләтләре турындагы вәгазь белән башлап җибәрде. Соңыннан дәресләр расписаниесе һәм сыйныфларга бүленеш мәсьәләләренә ачыклык кертелде. Җыелыш ахырында Аллаһы Тәгаләдән файдалы һәм бәрәкәтле гыйлемнәр сорап дога кылынды.

### ДАРТС БУЕНЧА ЯРЫШЛАР ҮТТЕ

Казан ислам колледжында (КИК) ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөселман яшьләре арасында дартс дип аталган спорт төре буенча шәһәркүләм ярышлар үткәрде. Дүшәмбе көнне узган әлеге чарада житмештән артык кеше катнашты. I урынга колліятнең III курс студенты Камалетдинов Айнур, II урынга "Мәрҗани" мәчетеннән Маһзанов Фәнис, III урынга КИКның I курс студенты Хвайдаев Бәхтияр лаек булды. Җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

### "ГАКЫЙДӘ" АУДИО-ДИСКЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең нәшрият бүлегендә mp-3 форматында "Гакыйдә" аудио-дискы дөнья күрде. Анда Рәшит Исаевның вәгазьләре тупланган. Киләчәктә нәшриятта ислам дине тәгълиматына караган башка төрле аудио-китаплар да чыгару күздә тотыла.

*DUMRT.RU*

# Мөхтәрәм укытучылар!

***Татарстан Руспубликасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән Сезне һөнәри бәйрәмегез - Укытучылар көне белән тәбрик итәм.***

***Укытучы - ул катлаулы һәм үтә дә җаваплы һөнәр. Теләсә кем бу белгечлекне сайларга кыймый, бөтен кешенең дә гомере буе остазлык итәргә батырчылыгы җитми. Бер уйласаң, мөгаллим - ул һөнәр генә түгел, ул - Аллаһы Тәгалә тарафыннан аерым кешеләргә җибәрелгән сәләт, талант.***



***Шуңа да укытучыларны Ул күпкырлы хезмәт ияләре итеп яралткан. Әйтик, бүгенге көндә Сез гыйлем генә биреп калмыйча, кешеләргә тормышта үз юлларын, кыйблаларын табарга булышасыз. Шуңа да укучылар өчен генә түгел, ә тулаем җәмгыятебез өчен һәрвакытта да үрнәк булып торасыз.***

***Вакыт кына түгел, замана таләпләре дә, укучылар да һәрдаим үзгәреп тора. Шуңа да карамастан, сезнең җаваплылык аз гына да кимеми. Сез, киресенчә, елдан-ел нәтиҗәле хезмәт күрсәтеп киләсез. Бары үз эшен ихластан яратып эшләгән һәм, бернинди киртәләргә дә карамастан, үз миссиясен дәвам иткәннәр генә уңышка ирешә ала.***

***Киләчәктә дә Аллаһы Тәгалә биргән авырлыкларда сынмыйча-сыгылмыйча, рухи яктан ныгырга һәм ихтыяр көчегезне арттырырга язсын. Эшләгән хезмәтегез сезгә бары тик шатлык, рухи канәгатьлелек һәм иҗади уңышлар гына китерсен!***

***Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә һәрберебезгә дә билгеләнгән вазифаларыбызда сабырлык, саулык һәм уңышлар насыйп әйләсә иде!***

*Ихтирам белән,*
*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# БҮГЕНГЕ ЯШЬЛӘРНЕҢ СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК, ДИНИ КҮРСӘТМӘЛӘРНЕҢ КЫЙММӘТЕ

***Хәзерге социаль-икътисади фактор яшьләрнең гомуми психоэмоциональ халәтенә гел уңай тәэсир итми. Шәһәр шартларында социаль тигезсезлектән килеп чыккан стресслар, күпчелек очракта, яшьләрнең үзләрен теге яки бу өлкәдә таба алмауга һәм үз өстендә эшләүләрен дәвамлы алып бармауга киртә була.***

Бу турыда үз вакытында немец социаль психологы Эрих Фромм җитәрлек дәрәҗәдә һәм ышандырырлык итеп кешеләр арасындагы икътисади һәм кулланучы мөнәсәбәтләре үсешен язып калдырган. Эш урыннары җитмәү, буш вакытыңны бәрәкәтле файдалану өчен шартлар булмау - шәхеснең эчке дөньясы структурасында җитди үзгәрешләр барлыкка китерә һәм төп каршылык туугa сәбәпче була: кеше үзе нинди һәм ул нинди булырга тиеш?

Бүгенге яшьләрне күбрәк үз белемнәрен һәм осталыкларын ничек кенә булса да югарырак бәяләү мәсьәләсе борчый, ә инде көтелгән нәтиҗәгә ирешә алмау - өметсезлеккә һәм, бигрәк тә, җитешрәк гаиләләрдән булган яшьләрнең үзләрен түбәнрәк тоюга китерә.

Бу - күпчелек очракта, ярарга тырышу, хөсетлек яки агрессия кебек тискәре күренешләргә сәбәп була. Моннан тыш, яшьләрнең бер өлеше спиртлы эчемлекләр һәм наркотик кебек сәламәтлеккә зыянлы матдәләр кулланып, аңнарын томалый башлый.

Әлеге күренеш - замана яшьләренең гомуми тискәре эмоциональ фонын күрсәтә. Хәзер (моңа хәтле мондый күренешнең күзәтелгәне юк иде) җәмгыять социаль-иерархияле баскыч буйлап үз урынын күтәрү өстендә эш алып бара. Бу - җәмгыятьнең гомуми идеологиясе формалашуга да, аерым шәхеснең шәхси үзаңы үсешенә дә нык тәэсир итә. Акча-финанс мәсьәләләре рухи үсешне икенче урынга куйды һәм юмартлылык, бер-береңә ярдәм итү, хөрмәт күрсәтү кебек кешелекнең төп кыйммәтләре кирәксезгә әйләнде.

**(Ахыры 3 нче биттә.)**

# ХӘТЕР АЕ

***Кайвакыт кайчандыр якын дуслар булып йөргән кешеңне очратасың. Очрашу шатлыгыннан ах-ух киләсең. Тик бер бәла - исемен хәтергә төшерә алмыйсың. Ул сиңа исемең белән эндәшә, син хәтер сандыгын актарасың, юк кына бит... Шундый да уңайсыз була. Әдәпле кеше булса, синең хәтерсезлегеңне аңлый, сиздермәскә тырыша, кайберләре исә йөзеңә туры бәреп: "Шулай инде, әллә кем булгач, безнең исемне дә онытасың", - дип, канга тоз сала.***

Явыз көчләрнең иң зур хыялы - кешеләрнең хәтерен югалтып, һәр кушканын сүзсез, карусыз үтәтеп, үзләренә хезмәт иттерү. Укып беләбез - сугыш вакытында фашистлар концлагерьларда әсирләрне хәтерсез калдыру ысулын эзләп, коточкыч экспериментлар ясаганнар. Әдәбиятта хәтерсез калдырылган адәм баласының ничаклы куркыныч, шул ук вакытта мескен җан иясе икәнлеген онытылмаслык итеп бөек язучы Чыңгыз Айтматов сурәтләде. Маңкорт дигән сүзне телебезгә ул кертте. Хәтернең никадәр кадерле нәрсә икәнлеген кешеләр һәрдаим киләсе буыннарның исенә төшереп тора. Әйтик, русларның "Иван, не помнящий родства" дигән әйтеме, үзеннән башка беркемне дә танырга, белергә теләмәгән адәм актыкларына әйтелә. Татарның исә миңа иң ошаган мәкале шул: "Киләчәккә бабаңның таягына атланып чап, тизрәк барып җитәрсең", - дип әйткән сүзләре.

Аерым кешеләрнең хәтерләрен югалтуы фаҗига булса, халыкның хәтерен югалтуы - үлемгә бәрабәр. Бигрәк тә кайчандыр фаҗигагә тарыган кавем аны хәтерендә сакламаса, яңа фаҗигаләргә юлыгып тора. Җиңелүдән гыйбрәт ала белмәгән һәм җиңелү ачысын бүтән татымас өчен көрәшмәгән милләт бетә, югала. Һәм аның бетүе, юкка чыгуына көенүчеләр күп булмый, сөенүчеләр күп була. Аяусыз тарих боларны үз сәхифәләрендә теркәп бара. Агрессив дәүләтләр тарихи хәтерне бетерү өчен ниләр генә кыланмый. Объектив күренеш дип, үз явызлыкларын акларга тырышалар. Хәтта үзеннән көчсезрәк халыкларның юкка чыгуын прогрессив күренеш дип оятсызланалар. Әгәр дә бүген җиңелүгә дучар ителгән халык тарихи хәтерен югалтмаса, аның киләчәге өметсез түгел. Өмет чаткысы һәрдаим ирекккә омтылганнарга юлны яктыртып тора, тарихның бер борылышында үзенең рухи бөтенлеген саклап калган кавемгә ирек кояшын күрү бәхете насыйп була. Адәм баласының ирекккә омтылу инстинктын гаепләргә берәүнең дә хакы юк. Хәтта без җаны юк дип санаган үсемлекләр дә ташларны тишеп чыгып үсә. Асфальтны тишеп чыккан чирәмне кемнәрнең күргәне юк. Үч алуга гына кайтып калган хәтер уңышка алып бармас. Үч алу түбән җанлы кешеләр гамәле. Әгәр дә син кайчандыр җиңелгәнсең икән, җиңүчедән генә түгел, үзеңнән дә сәбәпләрен эзләргә кирәктер.

**(Ахыры 2 нче биттә.)**



Зилә ВӘЛИЕВА:

# "ХӘЗЕРГЕ МӨСЛИМӘЛӘР АКТИВ ПОЗИЦИЯДӘ ТОРА"

**29 сентябрь көнне башкалабызда "Бүгенге җәмгыятьтә мөселман хатын-кызы" дип аталган бөтенроссия фәнни-гамәли конференция булып узды.**

Чараны Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифен үстерү фонды ярдәме белән Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте оештырды. Филология һәм сәнгать институты бинасында узган конференциянең төп максаты - мөслимәләрне борчыган мәсьәләләрне яктырту һәм бергә утырып аларның чишелеш юлларын эзләүдән гыйбарәт иде.






Җыенда Корьәннең рус телендәге тәфсирен (аңлатмасын) эшләгән Валерия (Иман) Порохова, "әл-Вәсатыйа" үзәге директоры урынбасары Галина Хизриева, "Россия" телеканалында "Мусульмане" тапшыруын алып баручы Динара Садретдинова, ТР Министрлар Кабинеты карамагындагы Гражданлык актларын теркәү (ЗАГС) идарәсе башлыгы Эльмира Зарипова, Мәскәүдә чыга торган "Мусульманка" журналы вәкилләре катнашты.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз, конференциядә катнашучыларны сәламләп, хатын-кызларның җәмгыятьтә зур урын тотуын билгеләп узды. Ул пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) вакытында да, үзгәртеп кору җилләре исә башлагач та, хатын-кызларның күпләп дингә килүләрен искәртеп узды. Бик күпләрнең остазы булган Рәшидә Исхакый, мөслимәләрнең яулыктан фотога төшү хокукына ирешкән Әлмира Әдиятуллиналарның хезмәтен хөрмәт белән телгә алды.

ТР Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева "Бүгенге җәмгыятьтә мөселман хатын-кызы" дип аталган бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең бик вакытлы уздырылуына басым ясады. Ул хәзерге җәмгыятьтә нәфис затларның үз урыннарын табуы, аларның төрле мөмкинлекләрдән файдалануы, тормышта үз-үзеңне ничек хис итүеңә кагылышлы мәсьәләләрнең көн үзәгендә торуын билгеләп узды.

Премьер-министр урынбасары үз чыгышында татар хатын-кызларын белемле итү юлында зур тырышлык куйган Мөхлисә Буби һәм Фатыйха Аитоваларны искә алып, аларның хәзерге мөслимәләр өчен үрнәк булып торуларын ассызыклап үтте.

Зилә Вәлиева, безнең көннәрдәге мөслимәләрнең дә актив позициядә булуларын, мөселман хатын-кызларын берләштерүче ТР Мөслимәләр берлеге һәм "Мөслимә" кебек иҗтимагый оешмаларның үз эшләре белән танылуы турында да әйтте. Ул мөслимәләрне, бар көчне бер йодрыкка туплап, социаль бурычларны хәл итү юнәлешендә эшләргә чакырды. Мөслимәләрне иҗтимагый эшкә тартуда бу беренче баскыч булачак, диде ул.

ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин билгеләп үткәнчә, әлеге конференция җәмгыятьнең төрле өлкәләрен берләштерә һәм бу мөслимәләр белән бәйле мәсьәләләрнең көн үзәгендә торуын күрсәтә. Марат Гатин сүзләренчә, игелеклелек, ярдәмчеллек һәм башка шундый әхлакый кыйммәтләрне нәкъ менә хатын-кызлар үзендә йөртә, аны башкалар күңеленә дә сала. Ә глобальләшү чорында исә бу кыйммәтләр артыкы планга күчә башлады. Марат Гатин, бу нисбәттән мөслимәләрне Татарстан мөфтияте белән берлектә уртак проектлар төзү эшчәнлегендә катнашырга чакырды.

КФУның Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов исә үз чыгышында "Мөселман мәгарифен үстерүгә ярдәм итү" федераль программасы турында сөйләп үтте, - дип яза tatar-inform.ru сайты.

**Римма ГАТИНА**

# ХӘТЕР АЕ

**(Ахыры. башы 1 чне биттә.)**

Октябрь ае татар халкы өчен фаҗигале ай. Дәүләтебезне югалту ачысын гасырлар буе татып киләбез. Ләкин без әле хәтеребезне югалтып бетермәгән халык. Хәтер көне дип билгеләгән көнебез бар. Тәнендә җаны булган татар ул көнне һәрвакыт истә тота. Үч алу өчен түгел, үзен саклап калыр, онытмас өчен. Тарихчыларыбыз мөстәкыйльлегебезне югалтуның сәбәпләрен эзли. Аның сәбәпләре төрле, әмма иң зурысы - милли идея тирәсендә җыела, берләшә алмаудыр. Безнең өчен иң зур сабак шул, хәтердә шул сабак сакланырга тиеш. Хәтер көнен октябрьнең икесеме, уникесе яисә унбишендә үткәрү турында бәхәсләр куерып ала. "Вакчыл" тарихчылар өчен төгәллек заруридыр, тик минем өчен ул алай ук әһәмиятле түгел. Татар кешесе октябрьнең ул көненә ничәмә еллар "әзерләнде". Тәхет өчен көрәш, уяусызлык, ваемсызлык, үзара ыгы-зыгыларның апогее гына октябрьнең шыксыз көненә туры килде. Минем өчен октябрь - тулаем хәтер ае. Гает бәйрәменә мөселманнар Рамазан ае буена ураза тотып киләләр бит. Октябрь аенда, минемчә, үзен татар дип санаган һәм татарлыгын югалтырга теләмәгән рухы ирекле кеше, хәтерен югалтканнарга ярдәм итү өчен дәвалану ысулларын өйрәтергә тиештер. Адәм баласы хәтерен һәм өметен югалтмаска тиешлеген, ни кызганыч, күпләребез онытa башлады. Дөресен әйтим, кайвакыт өметсезлеккә бирелеп: "Кем булып яшәсәң дә барыбер түгелмени?" - дигән уй килеп китә. Тамагың тук, өстең бөтен булса, шул җитмәгәнмени? Шуннан уйлыйм-уйлыйм да, туктале, дим, кешене кеше иткән тамак һәм өс бөтенлеге генә түгел бит. Тарихны искә төшерәм - азатлык өчен кешеләр ничаклы көрәшкәннәр. Нигә кирәк булган? Аллаһы Тәгалә дөньяны төрле-төрле итеп яраткан. Күпме төсләр бар табигатьтә, нинди генә агачлар, чәчәкләр, хайваннар юк. Нигә әле кешеләр бер төрле булырга тиеш? Кеше дә табигатьнең бер өлеше - табигать баласы ләбаса. Шуларны уйлаганнан соң рухымның бөтенлеген, бабаларымның хәтерен саклыйсы килү теләге тагын да көчәя, үземне ирекле җан итеп тоя башлыйм. Милләтем хәтерен югалтмаса, бу дөнья белән мәңгелеккә хушлашсам да, мине кемнәрдер хәтерләр, дигән өмет яшәү көчен арттыра. Шуңа күрә дә, октябрь - елап утыра торган ай түгел, яшәү өчен уйлану, рухи бөтенлеккә якынаю ае булырга тиештер.

***Туфан МИҢНУЛЛИН,***
***ТР Дәүләт Советы депутаты,***
***Татарстанның халык язучысы***

## Татарстан мөфтие Тарик Али Сардар белән очрашты

***5 октябрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз Корьән хафизлары әзерләүче дөньякүләм оешманың Галимнәр шурасы рәисе Тарик Али Сардар белән очрашты.***



Очрашуда Казанда үтәчәк Корьән хафизлары конкурсына бәйле сораулар каралды һәм киләчәктә дә бергә хезмәтттәшлек итү турында килешенде.

## Татарстанда үлем-китем очраклары кимеде

***ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, Татарстанның демографик халәтендә уңай үзгәрешләр күзәтелә. 2011 елның гыйнварыннан август аена кадәр аралыкта туучылар саны бакыйлыкка күчүчеләрнекеннән артып киткән.***

Анализланган чорда 32665 бала тууы һәм 31978 кешенең фани дөньядан китүе мәгълүм (үткән елның шул ук вакыт аралыгында бу сан 31974 кә 34103 чагыштырмасында булган).

Кан йөреше начарлану аркасында вафат булучылар саны - 12 процентка, миокард инфарктыннан үлүчеләр - 4,9 процентка, церебраль параличтан дөнья куячылар 8,7 процентка кимегән.

Яшь балаларның гомере өзелү очрагы 7 процентка кимеп, 1 мең тууычыга 5,3 не генә тәшкил итә. Ана кешеләрнең үлеме дә 2,4 процентка түбәнәеп, 100 мең кешегә 12,2 генә туры килүе хакында мәгълүм булды.

***TATAR-ISLAM.RU***

## "Алтын урта"да сезон ачылышы!

***Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге нигезендә эшләүче "Алтын урта" җәмгыяте үз чараларын башлап җибәрде. 5 октябрьдә мөфти Илдус хәзрәт Фәиз яшьләр белән очрашты.***

Нәзарәтнең конференц залында үткән әлеге очрашуга җитмештән артык яшьләр килде. Алар арасында Россия ислам университеты, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе, Казан ислам көллияте һәм дөньяви вузларның студентлары, укуын тәмамлап, эшләүче мөселман яшьләре дә бар иде.

Кичәнең төп темасы "Алтын урталыкны ничек табарга?" дип исемләнгән иде. Мөфти хәзрәт күбрәк шул турыда сөйләде, яшьләргә киңәшләрен җиткерде. Күп проблема һәм ялгышларның белемсезлектән килүенә басым ясады, урталыкны табар өчен гыйлемле булырга кирәклекне билгеләп үтте ул.

Илдус хәзрәт яшьләрнең сорауларына да җавап бирде. Аларны исә дини уку йортларын тәмамлагач, ни өчен дипломны ике-өч елдан соң гына бирүләре, "Авылга кайткан яшь имамнарга "өчесе", "җидесе", "кырыгы"н үткәрү мәсьәләсендә нишләргә?", "дингә каршы килүче дөньяви белгечләрнең фәнни хезмәтләрен өйрәнергәме?" кебек сораулар борчыды.

Яшьләр бигрәк тә мөфти хәзрәтнең гыйбрәтле хәлләр, тормыштан алынган мисаллар белән җавап бирүен ошатты. Очрашу ахырында "Алтын урта" яшьләре Илдус хәзрәтне Укытучылар көне белән тәбрикләде. Яшьләр арасында исә аның укучылары да бар иде.

Илдус хәзрәт Фәиз кичәне: "Бер-берегезне тәнкыйтьләмәгез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) дә: "Кардәшенең ялгышын яшергән кешенең гаепләрен Аллаһ Тәгалә кыямәт көнендә яшерер", дип әйтә. Аллаһка ышанырга, ә ничек ышанырга икәнлеге турында бәхәс алып бармаска, намаз укырга, әмма ничек намаз укырга кирәклеге турында бәхәсләшмәскә, Корьәнне укырга һәм кушылганнарны үтергә, ә аны җырлау-көйләү белән шөгыльләнмәскә киңәш итәм", дигән теләкләр белән тәмамлады.

"Алтын урта"ның киләсе зур чарасы 12 октябрьдә - Федераль милли-татар мохтәрияте рәисе, дәүләт дупутаты Илдар Гыйльметдинов белән булачак.

Ә 7 октябрьдә "Алтын урта"ның Кызлар клубы яулык бәйләү буенча мастер-класс үткәрергә җыена. Якшәмбе, 9ында исә кызлар белән велосипедта йөрү чарысын оештырырга исәплиләр.

# БЕРГӘЛЕКТӘ КӨЧ!

***- Актив тормыш позициясе булган, максатчан яшьләргә элек-электән югары бәя бирелгән. Бүгенге мөселман яшьләре арасында да андыйлар җитәрлек. Безнең көннәрдә мөселман өммәтен борчыган сорауларны үз эченә алган күп кенә форумнар, түгәрәк өстәлләр, акцияләр үтә, аларның әйдәп баручылары нәкъ менә яшьләр. Шуңа да берләшеп эшли башларга вакыт җитте, - дип билгеләп үтте Мөселман яшьләре берлеге оешмасы рәисе Рүзәл Әхмәдиев.***



Кыскача мәгълүмат. Әхмәдиев Рүзәл Раушан улы. КФУның юридик факультетының IV курс студенты. Күпләргә шагыйрь, гитара кылларын чиртергә яратучы, КВНчы, "Axelle" рэп группасының солисты, шулай ук "Идел" һәм "Сәләт" яшьләр үзәкләренең активисты буларак таныш.

- Мөселман яшьләре берлеген оештыруның төп максаты - мөселман яшьләрен, фикердәшләрне бер мәйданга туплап, үзебезнең идеяләр белән уртаклашу, җәмгыять өчен файдалы булган күмәк проектларны тормышка ашыру. Берлеккә инде "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе һәм Россия ислам университеты студентлары кушылды, хәзерге вакытта дөньяви уку йортларында укучы студентларны барлыйбыз. Атна саен җыелышлар үткәрергә уйлыйбыз, борчыган мәсьәләләрне чишү өчен генә түгел, ә үзара аралашыр, фикердәшләр табыр өчен дә.

- Рүзәл, берлек ни рәвешле үсәчәк?

- Иң беренче чиратта, төбәкләр белән эшләргә уйлыйбыз. Чөнки регионнардагы мөселман яшьләре күп очракта күләгә астында кала. Мөселман яшьләре берлеге ярдәме белән яшьләр үзләренең көчләрен тояр, аларның иҗади потенциаллары ачылыр, дип өметләнәбез. Бу - романтик һәм шул ук вакытта шактый җитди эш. Россиянең төрле шәһәрләрендә филиаллар ачу теләге дә бар. Үз шәһәрләрендә ачарга теләкләре булганнар берлеккә үзләренең тәкъдимнәре белән мөрәҗәгать итә алалар. Киңәш-тәкъдимнәргә без бары тик шат кына.

- Берлеккә нинди критерийларга карап сайлап алачаксыз?

- Иң мөһиме - теләк һәм актив булу. Без нииндидер таләпләр куеп һәм бары тик шулар аркылы гына яшьләрне җыярга уйламыйбыз. Безгә максатчан, актив, тормышта үзләренә нәрсә кирәклеген ачык күргән яшьләр кирәк. Бары шул яшьләр белән генә мөселман өммәтенең киләчәген күзаллап була.

Минем фикеремчә, мөселман яшьләрен шәһәрнең иҗтимагый тормышына кушып җибәрү яхшы булыр иде. Кагыйдә буларак, дөньяви уку йортлары студентлары өчен монда арадашчының кирәге юк, ә мөселман уку йортлары өчен нәкъ менә Мөселман яшьләре берлегенең арадашчы ролен башкаруы кирәк булачак. Безнең төп максат - игелекле гамәлләр, үзебезнең эшләребез ярдәмендә җәмгыятьтә ислам диненә, мөселманнарга карата (дөрес, хакыйкый) адекват бәя уяту. Һәм, гомумән, яшьләрдәге тулып торган энергия-көчне җәмгыять өчен файдалы эшләрдә куллану.

Әгәр сине әлеге язма кызыксындырса, үзең һәм үзеңнең проектың турында Мөселман яшьләре берлегенә белдерәсең килсә, берләшмә эшчәнлегендә катнашырга теләгең уянса, 8-927-421-8456 телефон номеры буенча яисә ruzal-mail@mail.ru электрон адресы буенча мөрәҗәгать итә аласың.

**Алинә БИКМУЛЛИНА**

# Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге Мамадышта булып кайтты



***ТР мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре Мамадыш районы яшьләре белән очрашты.***

Мамадыш мәдрәсәсе нигезендә быел оешкан "Сәлам" клубы мөселман яшьләре өчен очрашу, аралашу, фикер алышу мәйданына әверелгән. Яшьләр күптән түгел генә никах турында сөйләшү үткәргән, төркем булып Нократ елгасы буен җыештырган, бергә җыелып гөмбәгә барган... Шушы арада гына Өлкәннәр көненә туры китереп, ярдәмгә мохтаҗ әби-бабайларга булышып кайтырга да өлгергән алар.

Очрашуда "Сәлам" клубы "Алтын урта" филиалы буларак үз эшчәнлеген дәвам итәр, дип килешенде. Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге исә мамадышлыларга бу башлангычта ярдәм итеп торырга сүз бирде һәм үз эшчәнлекләре мисалында эш итәргә тәкъдим итте.

Мамадышта үткән очрашуда район мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миңлегалиев, мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин, "Сәлам" клубын оештыручылар - Ирек Нуриев белән Ранил Талипов һәм әлеге клубка йөрүче мөселман яшьләре катнашты. Мамадышлылар киләчәктә атна саен берәр кичә оештырырга, кызлар өчен аерым чаралар үткәрергә, "Ак яулыклы әбиләр" дип исемләнгән кичәләр башларга һәм авылларда да актив эшчәнлек алып барырга исәпләре булуын әйтте.

Диния нәзарәтеннән килүчеләр - Айнур Солтанов, Ләйсән Фәтхетдинова, Айдар Кәрибуллин аларны "Алтын урта"да үткән чаралар белән таныштырды, җәй көне узган "Проектлар мәктәбе"ннән видео-өзекләр күрсәтте һәм киләчәктә бергә эшләргә сүз куеште.

Очрашуга "Шәһри Казан" газетасы журналисты, яшь шагыйрь Фәнил Гыйләҗев тә барган иде, ул үзенең дини эчтәлекле шигырьләрен сөйләде.

**Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА**

# БҮГЕНГЕ ЯШЬЛӘРНЕҢ СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК, ДИНИ КҮРСӘТМӘЛӘРНЕҢ КЫЙММӘТЕ

**(Ахыры. башы 1 нче биттә.)**

Алар урынына усаллык, агрессия, үзең турында гына уйлау һәм хөсетлек кебек сыйфатлар тамыр җәйде.

Дини тәрбия алган кешеләрдә бөтенләй башка картина күзәтелә. Моңа мисал итеп, кешеләрнең теге яки бу ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмаган очракта да бик үк кискен рәвештә җавап кайтармауларын әйтеп узарга мөмкин. Психология фәненнән билгеле булганча, психикага яра салу очракларында кеше саклану механизмнарын активлаштыра. Күпчелек очракта, аларның хәрәкәтләре үз-үзеңне алдауга китерергә мөмкин. Бу механизмнар билгеле бер вакытка теге яки бу күренешнең психиканы яралау тәэсирен киметә, ләкин берникадәр вакыттан соң проблема үзенең барлыгын сиздерергә һәм ул бөтенләй башка яссылыкта ачылырга мөмкин. Махсус дини белемгә ия булган, Аллаһы Тәгаләгә ышанган кеше социаль тигезсезлекне алай ук кискен рәвештә кабул итмәячәк, аның өчен ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән сынау рәвеше генә.

Ләкин мондый нигезләмә дингә ышанучыларның барысына да түгел, ә бары тик дини белемгә ия булган һәм шуны үз яшәешләренә кабул иткән, әлеге юнәлешне әхлак нормасы итеп таныган кешеләргә генә хас.

Түбәндәге фактны да истән чыгарырга ярамый: киресенчә, дин әһелләренең дә билгеле бер өлеше невротик хәрәкәтләрдә чагылучы тискәре хисләр тоярга мөмкин. Бу хәл күзәтелгән очракта, шунысын да әйтеп узарга кирәк: үз-үзен шул рәвешле тоткан кешеләр психик яктан сәламәт түгел һәм алар динне башкалар өчен мөһим булмау компенсациясе итеп куллана. Мондый кешеләр категориясен дини фанатизм күзлегеннән чыгып анализлап карарга кирәк. Бу - дини күрсәтмәләрнең кеше психикасына уңай тәэсирен күрсәтә торган билге.

Икенче мөһим фактор булып, якыннарыңны югалткан очрактагы кайгы хисе тора. Күп кенә психологик мәктәп вәкилләре кешенең психик сәламәтлеге яхшыру очрагын диннән күрә. Бу - бигрәк тә, махсус дини хезмәт булдырылган хоспислар эшчәнлегендә актуаль. Үлем-китемнең тормыш тукталу булмавына ышанган кеше үзенең Аллаһы Тәгалә белән бәйләнешен сизеп, югалтуны җиңелрәк кичерә. Моннан тыш, дин, аерым алганда, ислам дине, авырлыкларга сабырлык күрсәтергә куша һәм артык үкенүне яратмый, кешегә үз эченә бикләнергә ирек бирми, көндәлек яшәешкә тиз арада кайтуны хуплый. Әлеге нигезләмә үкенеч хисен кечерәйтә һәм кешегә югалту ачысын тизрәк һәм җиңелрәк кабул итәргә булыша. Моннан тыш, әлеге күрсәтмәләрне күп кенә психологлар якыннарын югалткан кешеләрнең күңел газапларын җиңеләйтү өчен дә уңышлы куллана.

Өченче мөһим фактор булып - хәмер, наркотик һәм отышлы уеннарны катгый рәвештә тыйган система тора. Мөселман дини уку йортларында алып барылган эшчәнлектән чыгып, шуны әйтергә мөмкин: дөньяви уку йортларыннан аермалы буларак, аларда наркотик кулланучыларның бөтенләй күзәтелгәне юк. Кызганыч, наркотик матдәләр куллану очраклары ислам дине нормаларын үтәүчеләр, мөселманнар яшәгән яшьләр тирәлегендә дә бар (мисал өчен, Кабарда-Балкар, Төньяк Осетия - Алания, Адыгей, Башкортстан, Дагстан, Чечня Республикалары). Ләкин аларның саны алай ук күп түгел һәм монда төп нәтиҗәне дини тәрбия һәм әлеге уку йортларында дин әһелләре тарафыннан үткәрелгән профилактик чаралар бирә.

Моннан тыш, күп өлеше тыю рәвешендә булган дини күрсәтмәләр, кеше олыгайган саен, аның үзаңын һәм тәртибен бер рәвештә тотып, үрнәк шәхес формалашуга китерә. Шулай итеп, диннең, безнең мисалда исә ислам диненең, сәламәт яшәү рәвеше генә түгел, гомумән, кешелекне саклауда көчле фактор булуы ачык аңлашыла. Ислам динен кешеләрне аеру өчен түгел, ә киресенчә, аларны берләштерү, исән-имин һәм яхшы тормышта яшәтү өчен куллану мөһим. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә әйтелгәнчә: "Аллаһ каршында иң хәерлеләрегез - күркәм холыкка ия булганнарыгыздыр". Әлеге хәдис үз холкыбызны кайгырту тиешлегенә дәлил түгелмени?!

Әйләнә-тирәдәгеләргә безнең белән яшәү җиңел булсын өчен, мөселман булмаганнарга әхлак һәм тәртип ягыннан да үрнәк булырга кирәк!

Танылган Австрия психоаналитигы Альфред Адлер (ул фәнни психологиядә гаять дәрәҗәле кеше) шуны өйрәтеп калдырган: депрессиядән арынырга теләгән кеше ике атна дәвамында хәленнән килгәнчә үзенең әйләнә-тирәсендәгеләргә мөмкин кадәр күбрәк яхшылык эшләргә тиеш. Без, мөселманнар, яхшылыкны ике атна дәвамында гына түгел, гомеребез буе кылырга, һәрхәлдә, шуңа омтылырга тиешбез. Бу безгә депрессияләр (ул һәрбер кешенең тормышында була торган гадәти күренеш) белән көрәшү өчен генә түгел, ә әйләнә-тирәдәгеләргә үз динеңне таратырга да ярдәм итәчәк һәм ахирәт тормышына әзерләнү өчен нигез булып торачак.

**ISLAM.RU сайты хәбәрләрен файдаланып, Нияз САБИРҖАНОВ**



## Бәла бәхеттән тизрәк йөри икән...



***1 октябрь көнне ТР Фәннәр Академиясенең Тарих институты директоры, җәмәгать эшлеклесе Рафаэль Хәкимовның бердәнбер кызы машинасы белән бәрелеп вафат булды.***

Камилә Казанга килгән вакытта үзе идарә иткән машина белән юл һәлакәтенә очраган һәм шунда ук вафат булган. Һәлакәт урынына тиз арада килеп җиткән медиклар да яшь автолединың гомерен саклап кала алмаган.

К.Хәкимова быел Казан федераль университетының ВМК факультетын тәмамлаган булган. Дүшәмбе көнне кыз башкалабызның Яңа бистә зиратына бабасы, шагыйрь С.Хәким янына җирләнде.

Исегезгә төшерәбез: татар халкының бөек шагыйре Сибгат Хәкимнең тууына быелның 4 декабрендә 100 ел булачак. Камилә дәү әтисенең бу юбилеен күрә алмыйча арабыздан китеп барды.

ТРмөселманнары Диния нәзарәте Рафаэль Сибгат улының һәм аның тормыш иптәше Мәүлидә ханымның тирән кайгысын уртаклаша. Авыр кайгылы көннәрдә аларның гаиләсенә сабырлык, түземлелек тели.

## ТИЗРӘК НАМАЗГА БАСАСЫ ИДЕ...

***Мин мөселманнар яшәгән җирлектә торам, әти-әнием - дин тотучы мөэмин-мөселман (алар намазларын калдырмый, зәкәтне дә вакытында биреп бара). Ләкин нигәдер мин әлегә кадәр намазга баса алмыйм, миңа нәрсәдер комачаулый сыман. Әти-әнием мине намаз укырга мәҗбүр итә димәс идем, алар: "Вакыты җиткәч, үзең килерсең", - ди... Дөнья тормышы минем өчен мәгънәсен югалта башлады кебек тоела. Зинһар өчен, киңәш бирсәгез иде, миңа нишләргә?..***

**ДИН БЕЛГЕЧЕ КИҢӘШЕ:**

- Намазга никадәр иртәрәк бассагыз, шулкадәр хәерлерәк булыр. Аннан соң күңелегезгә җиңеллек килгәнен үзегез дә сизә башларсыз. Изге гамәлләр кылу өчен кешенең нәфсе ирек бирми, шуңа күрә дә үз нәфсең белән көрәшергә кирәк. Хак Тәгалә үзенең фарыз гамәлләрен үтәгәннәргә савап язылачагын һәм Ул кушканча яшәмәгәннәргә җәза биреләчәген вәгъдә итә. Вәгазьләр тыңлап, дини өйрәтмәләр укуөйрәнү белән мәшгуль булсагыз, намазга басу теләгегез көчәер; ихтыяр көче булдырып, туры юлны табарсыз. Намаз укымау һәм аны калдыру - олы гөнаһларның берсе, ул адәм баласын кяферлеккә алып килергә мөмкин. Әгәр дә кеше мөэмин-мөселман дәрәҗәсенә ирешә алмыйча дөнья белән хушлашса, ул җәһәннәмгә эләгәчәк. Аллаһы Тәгалә сезне тыйганнарыннан тыеп, тиз арада дөрес, тугры юлга басарга ярдәм итсә иде!..



**ПСИХОЛОГ ФИКЕРЕ:**

- Гадәттә, курку хисе кешегә ниндидер эш-гамәлләрне башлап җибәрергә ирек бирми. Бәлки, сез намаз укый башлаганнан соң аны ташлармын, дип шүрлисездер? Бу очракта курку урынсыз, киләчәктә нәрсә буласын бары тик Аллаһы Тәгалә генә белә. Шайтан коткысына бирелмәгез. Курку-ялкаулыкларыгызны җиңеп, мөселманнарга фарыз итеп билгеләнгән гамәлләрне аз-азлап үти башлагыз. Шул рәвешле, Аллаһка якынайганнан-якыная барырсыз. Кеше еш кына рухи киеренкелек аркасында үзенә кирәгеннән артык йөк ала һәм шуңа күрә дә аның эш-гамәлләре дәвамлы булып бармаска мөмкин.

**Җавап islam.ru сайтыннан алынды**

## Урыныгыз җәннәттә булсын, Нәҗип хәзрәт!



***2 октябрь көнне башкалабыздагы мөселман җәмәгатьчелегенә кайгылы хәбәр килеп ирешә: ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы әгъзасы, Казандагы "Рамазан" мәчетендә озак еллар имам-хатыйб булып эшләгән Нәҗип хәзрәт Гайнетдиновның 82 яшендә йөрәге тибүдән туктады.***

Дүшәмбе көнне хәзрәтне туганнары, ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре, мәркәзебез мөхтәсибәте, мәхәллә халкы соңгы юлга озатты. "Рамазан" мәчетендә Казан шәһәре имаммөхтәсибенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов тарафыннан җеназа намазы укылды.

Н.Гайнетдинов - халкыбызга Казан шәһәренең Киров районында башкарган игелекле гамәлләре аша яхшы таныш. Аның кайгыртучанлыгы, ярдәме белән мәхәллә мәдрәсәсе өчен бина сафка басты. Соңгы елларда тынгысыз йөрәкле хәзрәт картлар йорты салырга тотынган иде.

Нәҗип Минһаҗ улы 1929 елның 1 гыйнварында Оренбург өлкәсенең Мостай авылында дөньяга килә. Мәктәптә урта белем ала. Аннан соң контроль-үлчәү приборлары һәм автоматика (КИПиА) буенча мастер булып эшли. Булачак хәзрәт дини белемне Казанның "Солтан" мәчете каршындагы мәдрәсәдә ала.

Нәҗип Гайнетдинов олы тормыш юлы үтә: 1941-1944 елларда Олы Әшнәк авылы күмәк хуҗалыгында бил бөгә; 1945-46 нчы уку елында Казан шәһәрендәге 22 нче мәктәпне тәмамлый; 1948-1953 елларда армия сафларында хезмәт итә; аннан соң 40 нчы заводка эшкә урнаша һәм 1989 елга кадәр, ягъни лаеклы ялга чыкканчы шунда эшли.

1998 елда Казандагы "Рамазан" мәчетенең имам-хатыйбы итеп сайлана. Ул ике бала тәрбияләп үстерде.

Быелның яз айларында Нәҗип хәзрәт, сәламәтлеге какшау сәбәпле, имамлык итүдән туктарга мәҗбүр була. 31 майда булып узган ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумында Н.Гайнетдинов мөфтиятнең Аксакаллар шурасы әгъзасы итеп сайлана.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов Н.М.Гайнетдиновның вафаты уңаеннан хәзрәтнең туганнарының, балаларының, якыннарының, "Рамазан" мәхәлләсе халкының тирән кайгысын уртаклашты.

Нәҗип хәзрәт Казанның Юдино посёлогы зиратына җирләнде.

## Г.Камал исемендәге театрда – ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫННАН БЕРЕНЧЕ КАЗЫЙ МӨХЛИСӘ БУБИ ТУРЫНДА СПЕКТАКЛЬ ПРЕМЬЕРАСЫ



***Спектакльнең режиссёры Илгиз Зәйни сүзләренчә, "Үлеп яратты" спектакле - иманлы кешенең көче турында, - дип яза tatar-inform.ru сайты.***

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры яңа 106 нчы сезонында Ркаил Зәйдулланың татар кызлары өчен беренче мәдрәсә оештыручы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, хатын-кызлардан беренче казый Мөхлисә Бубига багышланган "Үлеп яратты" дип исемләнгән пьесасын сәхнәләштерәчәк. Премьераның режиссёры - яшь талант иясе Илгиз Зәйниев.

Сталин репрессияләре корбаны булган, төрмәдә атып үтерелгән Мөхлисә Буби ролендә - Нәҗибә Ихсанова һәм Дания Нуруллина.

Ркаил Зәйдулланың бу әсәре "2010 елның яңа татар пьесасы" конкурсында ТР Мәдәният министрлыгының махсус премиясенә лаек булган иде. Премьера "Һөнәр" дип аталган яшь татар режиссурасы фестивале кысаларында декабрь аенда булачак.

Ркаил Зәйдулла ни өчен Мөхлисә Буби язмышына мөрәҗәгать иткән соң? 4 октябрь көнне театрның 106 нчы сезоны ачылуга багышланган матбугат очрашуында бу сорауга җавап биреп, әлеге темага мөрәҗәгать итүнең сәбәбе бүген мәгариф өлкәсендәге вәзгыятькә бәйле булуын әйтте.

Ул тарихта нык эз калдырган Мөхлисә Бубиның абыйлары белән берлектә татар халкы тормышында зур эз калдырганлыгын, алар оештырган Иж Бубый мәдрәсәсендә безнең генә түгел, башка милләт балалары да белем алуын билгеләп үтте. Мәдрәсәнең программасының бигрәк тә гуманитар юнәлештә бүгенге югары уку йортлары программасыннан аерылмавын белдерде.

Ркаил Зәйдулла Мөхлисә Бубиның гомеренең соңгы көннәрен төрмәдә уздыруын, анда вакытта беркемне дә сатмавын һәм иманлы килеш үлеп киткәнлеген әйтте. Мөхлисә Бубиның татар хатын-кызларына үрнәк булырлык шәхес булуын белдерде.

Спектакльнең режиссёры Илгиз Зәйни сүзләренчә, әлеге спектакль - иманлы кешенең көче турында. "Бу тема безнең драматургия өчен әле яңа. Ул тамашачылар өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз", - диде режиссёр.

**Римма ГАТИНА**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 8.10.2011 | 05:32 | 06:58 | 13:02 | 16:03 | 18:02 | 19:29 |
| Якшәмбе | 9.10.2011 | 05:34 | 07:00 | 13:02 | 16:01 | 17:59 | 19:26 |
| Дүшәмбе | 10.10.2011 | 05:36 | 07:02 | 13:02 | 15:59 | 17:57 | 19:23 |
| Сишәмбе | 11.10.2011 | 05:38 | 07:04 | 13:02 | 15:57 | 17:54 | 19:21 |
| Чәршәмбе | 12.10.2011 | 05:39 | 07:06 | 13:02 | 15:54 | 17:52 | 19:18 |
| Пәнҗешәмбе | 13.10.2011 | 05:41 | 07:09 | 13:02 | 15:52 | 17:49 | 19:16 |
| Җомга | 14.10.2011 | 05:43 | 07:11 | 13:02 | 15:50 | 17:47 | 19:14 |

*Мәгълүматлар muslem.ru сайтыннан алынды*

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №8 (105) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзеклләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-508
**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 6 октябрь, 14.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлдә.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**